| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МИЧУРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2024 елның 10 июле | №14 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 20 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» (2023 елның 1 августындагы 27 номерлы үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 20 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» (2023 елның 1 августындагы 27 номерлы үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик затның үлеменнән соң яки аны үлгән дип игълан итүдән соң өч еллык срокның 2024 елның 1 гыйнварыннан Гражданлык процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки барлык варислар мирас алудан баш тартса, аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын әйтмәсә»;

б) 1 нче пунктның 8 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) 2024 елның 01 гыйнварына 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча бурычлар булу»;

в) карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 10 һәм 11 пунктчалары белән тулыландырырга:

«10) 2024 елның 1 гыйнварына варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларның бурычлары булуы;

11) 2024 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән судка аны түләтү турында гариза бирү срогы тәмамланганнан соң физик затлардан җирле салымнар буенча 500 сумнан артмаган бурычлар булуы.»;

г) карарны түбәндәге эчтәлектәге 2 пункт белән тулыландырырга:

«2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып торалар:

1) карарның 1 пунктындагы 1, 10 пунктларында күрсәтелгән нигез булганда:

- физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

- үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

- мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүматлар булмау турында салым органы белешмәсе;

2) карарның 1 пунктының 8 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

- салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) карарның 1 пунктының 11 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

- салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.»;

д) 2, 3, 4, 5 пунктларны 3, 4, 5, 6 пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин исемендәге п.п., Совет ур., 26-административ бина, Совет ур., 28-СДК; Яңа Сережка авылы, Үзәк ур., 9-СДК, Үзәк ур., 15-нче мәктәп йорт адресы буенча урнашкан торак пунктның мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Р.Ә.Иванова